Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бута авыл Советы

КАРАР

19 май 2023 ел № 75

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районың Бута авыл җирлеге Уставының XIV бүлеге нигезендә, 2023 елның 14 мартындагы ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, 2022 елның 17 маендагы № 02-08-02/227, 2023 елның 29 мартындагы №02-08-02/118 Әлмәт шәһәр прокуратурасының протестларын карап

Бута авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бута авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бута авыл җирлеге Уставындагы үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирлеге Уставына үзгәрешләрне теркәгәннән соң Бута авылы, Сельская урамы, 28А йорт, территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бута авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Бута
авыл җирлеге башлыгы Д.Е. Абрамов

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы
Бута авыл Советының 19 май
2023 ел № 75
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бута авыл җирлеге Уставында үзгәрешләр

1) 10 статьяда:

а) 4 өлешнең 3 пунктында «авыл җирлеге башлыгы» сүзләрен «авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлештә «авыл җирлеге башлыгы» сүзләрен «авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә, «авыл җирлеге башлыгының карары» сүзләрен «авыл җирлеге башкарма комитеты карары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлешнең икенче абзацында «авыл җирлеге сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба - сайлау комиссиясе)» сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 7.1 өлеш өстәргә:

«7.1. Җирле референдумда яшәү урыны авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары катнашырга хокуклы. Россия Федерациясе гражданнары җирле референдумда яшерен тавыш биргәндә гомуми тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә катнаша»;

2) 11 статьяның 4 өлешендәге икенче абзацында «авыл җирлеге сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 12 статьяда:

а) 5 өлештә «авыл җирлеге сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 нче өлештә беренче җөмләдә «авыл җирлегенең сайлау комиссиясе» сүзен «сайлау комиссиясе» сүзенә алыштырырга, икенче җөмләдә «сайлау комиссиясе утырышларын» сүзләрен «сайлау комиссиясе утырышы» сүзләренә алыштырырга;

в) 12 өлештә «Авыл җирлеге сайлау комиссиясе» сүзләрен «Сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

4) 16 статьяның 3, 4 өлешләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ачык тыңлауларга чыгарылырга тиеш:

1) авыл җирлеге Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында авыл җирлеге Советы карары проекты, авыл җирлеге Уставына, уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Конституция яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелү очракларыннан тыш;

2) җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән белдерелгән авыл җирлеге халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш.»;

4. Ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм халыкка ачык тыңлаулар уздыру вакыты һәм урыны турында, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан хәбәр итүне, шул исәптән аны җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

AnyScanner

челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән алдан таныштыруны яисә җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үз эшчәнлеге турында мәгълүматны «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасының рәсми сайтында яисә Җирлек җирлегендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, муниципаль берәмлек халкы тарафыннан муниципаль хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен, шул исәптән рәсми сайт ярдәмендә, күрсәтү мөмкинлеге, Поселение халкының гавами тыңлауларында катнашуны, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итә торган башка чаралар, кабул ителгән карарларның нигезле булуын да кертеп, шул исәптән аларны рәсми сайтта урнаштыру юлы белән бастырып чыгару (халыкка җиткерү) мөмкинлеген күз алдында тотарга тиеш.»;

5) 21.1 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл торак пунктының старостасы, составына әлеге авыл торак пункты керә торган авыл җирлеге советы тарафыннан авыл торак пунктының гражданнар җыены тәкъдим итү буенча билгеләнә. Авыл торак пунктының старостасы, әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары, яисә тәкъдим ителгән көнгә 18 яшькә җиткән һәм шушы авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

б) 3 өлештә «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган авыл җирлеге Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш» сүзләрен өстәргә,»;

в) 4 өлешнең 1 пунктында «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң «, 4 өлешнең 1 пунктында «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган авыл җирлеге Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә,» сүзләрен өстәргә.;

6) 25 статьяда:

а) 2 өлешнең 2 пунктының а, б) пунктчаларында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 8 өлештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгын (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

в) 9 өлештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгын (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

7) 27 статьяның 1 өлешендә «авыл җирлеге сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

8) 28 статьяның 1 бүлегендә:

а) 13 пунктны төшереп калдырырга;

б) 25.2 һәм 26 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25.2) биләгән биналарны (торак йортларны да кертеп) тоту таләпләрен, корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен тиешле биналарның һәм корылмаларның тышкы кыяфәтен һәм коймаларын, төзекләндерү эшләре исемлеген һәм аларны үтәү ешлыгын билгели торган авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау; бина (алардагы биналар) милекчеләренең һәм янәшәдәге территорияләрне төзекләндерүдә корылмаларның катнашу тәртибен билгеләү;

26) авыл җирлеге чикләрендә урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый атамаларны үзгәртү, гамәлдән чыгару (муниципаль районның федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларыннан, җирле әһәмияттәге);»;

AnyScanner

9) 35 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1.1 өлеш өстәргә:

«1.1. Депутат җитди сәбәпләрсез алты ай дәвамында авыл җирлеге Советының барлык утырышларында катнашмаган очракта, авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре авыл җирлеге Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

10) 37 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

11) 38 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Авыл җирлеге башлыгы авыл җирлеге Советына үз эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында еллык хисапларны тапшыра, авыл җирлеге башлыгы Башкарма комитетны җитәкләгән очракта, башкарма комитетның һәм аның карамагындагы башка җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән авыл җирлеге Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында, хисап бирә.»;

12) 41 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

13) 44 статьяның 7 пунктындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- адреслы объектларга адреслар тапшыра, авыл җирлеге чикләрендә адресларны үзгәртә, юкка чыгара, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыра;»;

14) 46 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

15) 55 статьяның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис) (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләренә алмаштырырга»;

16) 56.1 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

в) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

17) 57 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

б) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

в) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

г) 5 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

д) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

е) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

ж) 11 өлешнең 1) пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

з) 14 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

18) 61 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

AnyScanner

«5. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.».

Бута
авыл җирлеге башлыгы Д.Е. Абрамов

AnyScanner